Рус мәктәбенең татар төркемендә укучы балалар өчен
татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәре

11нче сыйныф
Үткәрү вакыты 180 мин.

## I. ТЕСТ:

Дөрес җавапларны билгеләгез: (1әр балл)

1. **“Йөзек кашы” (Ф Хөсни) әсәренең жанры:**

а) роман — ә) поэма
б) хикәя — в) шигырь

2. **М.Хәбибуллинның “Кубрат хан” әсәре кайсы чорда иҗат ителгән:**
а) XX гасырда
б) Алтын Урда чорында
в) XIX йөздә

3. **“Язгы аҗаган” әсәренең төзелешен билгеләгез, ул ничә бүлектән тора.**
а) 10 ел – 10 бүлек
б) 2 гасыр – 2 бүлек
в) 7 көн – 7 бүлек

4.**Йолаларның кайсы халыкныкы булуын билгеләгез:** (1әр балл)
а) Покрау ___________________________
ә) Уярня ___________________________
б) Нардуган ___________________________

## II. БИРЕМНӘР:

1. **Х. Туфанның “Кайсыгызның кулы җылы” шигыре кайчан, нинди шартларда языла? Әсәрдәге хис-кичерешләр хакында фикер йөртегез. (10 балл)**

________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

2. **Әдәби тропларга билгеләмә бирегез. Тропларның төрләренә мисаллар китерегез, аларның әсәрдәге функциясе хакында фикер йөртегез. (**9 баллга кадәр).

**3. Бу юллар кайсы әсәрдән? Авторын, хикәянең исемен языгыз. Төп геройны характерлагыз** (10 балл).

З а р и ф ***(утырган урыныннан кузгала, як-ягына, аннары күккә карап куя).*** Өянәкләрем кузгалып тотлыга башлаганда, вакыты-вакыты белән телсез калып торгач, мин курыктым. ***(Хәбибнең җырлавы ишетелә.)*** Ләкин бөтенләй үк котсыз калдым дип әйталмыйм.

Күке телсез калганнан урман яшәүдән туктамас, дидем мим үземә. Ләкин барыбыз да телсез калсак?.. Мин инде үзем, әйтәсемне әйттем, җырлыйсымны җырладым. Ә миннән соң барысы да телсез булса?! «Телсез» сүзенең син аңламый торган мәгънәсеннән курыктым мин. Ә менә Зыятдинның исән калып балалар, оныклар үстергәнен белгәч, оныгының телле икәнен күргәч вә ишеткәч, минем өметемнең ялкыны югары күтәрелде. ***(Кычкырыбрак.)*** Сугышта винтовканы телсез иткән тел әле яшәячәк ул! Винтовканы телсез калдырган җырны ничек үтереп булсын икән?! ***(Җыр көчәя.)***

**4. Бирелгән сүзләрдән танылган авторның шигырь юлларын төзегез, авторын, шигырьдә бирелгән хис-тойгыны билгеләгез.** (10 балл).

Хуш, юллыйм, сиңа, соңгы, барсын, сәламемне, аркылы, ялкыны, сиңа, кайнар җилләр, сәлам, йөрәгемнең, булып, сүнмәс, акыллым.

**<u>Барлыгы 45 балл</u>**